ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Тукай районының Мартыш авылын бетерү турында һәм «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 534-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Тукай районының Мартыш авылын бетерү турында һәм «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 534-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2398-VI ДС

Проект Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы тарафыннан кертелә

# «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ РАЙОНЫ МАРТЫШ АВЫЛЫН БЕТЕРҮ ТУРЫНДА ҺӘМ «ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ ҺӘМ АНЫҢ СОСТАВЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ ТЕРРИТОРИЯЛӘРЕ ЧИКЛӘРЕН БИЛГЕЛӘҮ ҺӘМ АЛАРНЫҢ СТАТУСЫ ТУРЫНДА» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ХАКЫНДА» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Тукай районы Мартыш авылын бетерергә

**2 статья**

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварендагы 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (үзгәрешләр: 2014, № 12 (VI өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 4 (I өлеш); (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 12 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2012, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:


1) 3 статьяның җиденче абзацында «Мартыш авылы»;

2) 1 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тукай муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

## «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## <u>карта-схемасы</u>




**Шартлы билгеләр**

- муниципаль район чиге
- 11 - тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- жирлекнең административ үзәге
- муниципаль районның административ үзәге

**Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы**

| | |
|---|---|
| 1 (64) – 8 (66) | - Менделеевск муниципаль районы |
| 8 (66) – 9 (67) | - Әгерже муниципаль районы |
| 9 (67) – 21 (68) | - Минзәлә муниципаль районы |
| 21 (68) – 26 (86) | - Сарман муниципаль районы |
| 26 (86) – 37 (87) | - Зәй муниципаль районы |
| 37 (87) – 43 (62) | - Түбән Кама муниципаль районы |
| 43 (62) – 44 (63) | - Алабуга муниципаль районы |
| 44 (63) – 56 | - «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге |
| 56 – 1 (64) | - Алабуга муниципаль районы |

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче авыл җирлекләре

| Карта-схемада номеры | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Әҗмәкәй авыл җирлеге |
| 2 | Бәтке авыл җирлеге |
| 3 | Биклән авыл җирлеге |
| 4 | Боерган авыл җирлеге |
| 5 | Борды авыл җирлеге |
| 6 | Иштирәк авыл җирлеге |
| 7 | Калмаш авыл җирлеге |
| 8 | Калмия авыл җирлеге |
| 9 | Князево авыл җирлеге |
| 10 | Комсомолец авыл җирлеге |
| 11 | Круглое Поле авыл җирлеге |
| 12 | Күзкәй авыл җирлеге |
| 13 | Кече Шилнә авыл җирлеге |
| 14 | Мәләкәс авыл җирлеге |
| 15 | Мусабай-Завод авыл җирлеге |
| 16 | Түбән Суыксу авыл җирлеге |
| 17 | Яңа Троицкий авыл җирлеге |
| 18 | Сәмәкәй авыл җирлеге |
| 19 | Иске Абдул авыл җирлеге |
| 20 | Иске Дөреш авыл җирлеге |
| 21 | Теләнче-Тамак авыл җирлеге |
| 22 | Шилнәбаш авыл җирлеге |
| 23 | Яңа Бүләк авыл җирлеге |

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

### Кыскача характеристика

Мартыш авылы (алга таба - Мартыш авылы) Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге территориясендә, Мартышка елгасының үрге агымында, Түбән Кама сәнәгать узелы предприятиеләренең сәнәгать мәйданчыкларыннан 1550 м көньякта урнашкан.

1678 елдан Бачкеева Пустошь (Бекчюрова Пустошь) буларак билгеле, революциягә кадәрге вакытта шулай ук Мартыш Баш буларак искә алына. XVIII-XIX гасырларда халкы дәүләт крестьяннары категориясенә караган. Игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү, арбалар һәм чаналар ясау белән шөгыльләнгәннәр. XX гасыр башында бирєдә су тегермәне, ярма чистарту җайланмасы эшли.

1920 елга кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Афонасовский волосте составына керә. 1920 елдан – Минзәлә, 1922 елдан ТАССР Чаллы кантоннары составында. 1930 елның 10 августыннан – Чаллы районында (1976 елның 20 апреленнән Тукай районында). Төп халыкын керәшеннәр тәшкил иткән.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге чикләрендә урнашкан.

2010 елда күчерүгә әзерлек кысаларында муниципалитет инициативасы буенча Татарстан Республикасы Тукай районы буенча «Техник инвентиризация бюросы» Территориаль бүлекчәсе тарафыннан Мартыш авылында урнашкан күчемсез милек объектларына техник инвентаризация үткәрелде. Барлыгы 104 җир кишәрлеге барлыгы ачыкланды, барысында да биналар төзелгән.

Теркәлгән халыкның төп категориясе – пенсионерлар.

### Санитар-эпидемиологик һәм экологик торыш

Тукай районы Мартыш авылы – сәнәгать мәйданчыгына иң якын урнашкан торак пункт. Сәнәгать мәйданчыгының шартлы чигеннән торак пунктка кадәр ераклык 1550 м тәшкил итә.

Мартыш авылында яшәүчеләрдән торак пункт буйлап ага торган Мартышка елгасының һәм ике чишмәнең химик матдәләр белән пычрануына беренче тапкыр шикаятьләр 2008 елның 10 январеннан килә башлый. Шул көннән башлап торак пунктның санитар-эпидемиологик һәм экологик торышы табигать саклау хезмәтләре тарафыннан даими контрольгә куела.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Кама арьягы территориаль идарәсе үткәргән су объектының гидрохимик торышын тикшерү мәгълүматлары буенча Мартышка елгасының бөтен су җыю мәйданы буенча нормативлардан артык үзенчәлекле химия приоизводствосы матдәләре белән пычрану эзләре күзәтелә. Мәсәлән, 2008 елның 19 сентябрендәге 75 номерлы табигый җир өсте суларын анализлау нәтиҗәләре беркетмәсе аммоний ионы буенча 3 тапкыр, нитритлар буенча 1,5 тапкыр, феноллар буенча 6 тапкыр, формальдегид буенча 1,4 тапкыр рөхсәт ителгән чик концентрациясе нормативларыннан артуны күрсәтә. 2008 елның 9 декабрендәге 94 номерлы беркетмәдә нефть продуктлары, метанол,

формальдегидның рөхсәт ителгән чик концентрациясе нормативларына максималь якын булган чикләрдә булуы теркәлгән.

Туфракта толуол һәм нефть продуктларының артып китүе ачыкланган, феноллар, бензол, этилцеллозольван булуы билгеләнгән.

Җир өсте су объектының пычрануы Мартышка елгасыннан 0,51 м ераклыкта урнашкан чишмә каптажларының пычрануына китергән. Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлеге мәгълүматлары буенча чишмәләрдә суның фенол белән пычрануы даими рәвештә раслана, бу СанПИНның эчә торган суга карата билгеләнгән таләпләренә туры килми; пычратучы матдәләрнең рөхсәт ителгән чик концентрациясе нормативларыннан артуы 1,9 дан 11,9 тапкырга кадәр тәшкил иткән.

Составында Тукай районы территориясендә эшчәнлек алып баручы барлык табигать саклау хезмәтләре вәкилләре булган комиссиянең эш нәтиҗәләре буенча су объектларын пычрату чыганагы билгеләнмәгән.

Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Кама аръягы территориаль идарәсе үткәргән аналитик контроль нәтиҗәләре буенча атмосфера һавасында 2008 елда гына формальдегид буенча – 4,5 тапкыр, фенол буенча – 2,7 тапкыр, этилбензол буенча 22 тапкыр арту теркәлгән.

Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлеге тарафыннан атмосфера һавасында ацетонның 1,4 тапкыр артуы теркәлгән.

**Күченүнең норматив-хокукый базасы**

«Түбән Кама шәһәренең һәм Түбән Кама районының әйләнә-тирә мохитен саклау буенча беренче чираттагы чаралар исемлеге турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 21 апрелендәге 197 номерлы карарын үтәү йөзеннән, 2007 елда «Түбән Кама сәнәгать узелының бердәм (хисап) санитар-күзәтү зонасы» проекты эшләнде. Проектның заказчысы – «ТАНЕКО» ААҖ. Эшләүче – «КНПУ «Оргнефтехимзавод» ААҖ.

Түбән Кама сәнәгать узелы составында 39 предприятие исәпкә алынган, аларның һәрберсе Түбән Кама шәһәренең һәм аңа якын торак пунктларның әйләнә - тирә мохитенә төрле дәрәҗәдә йогынты ясый, шуларның берсе генә - «ТАНЕКО» ААҖ төзелеш стадиясендә булган, ягъни файдаланылмаган.

2008 елда Проект Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә экспертиза узды. «Ф.Ф. Эрисман исемендәге федераль гигиена үзәге» Федераль дәүләт фән учреждениесенең уңай эксперт бәяләмәсе алынган. (Мәскәү ш.)

Түбән Кама сәнәгать узелының бердәм (хисап) санитар-саклау зонасы чикләре Татарстан Республикасы буенча баш дәүләт санитар табибының 2008 елның 15 июлендәге 11/16861 номерлы карары белән билгеләнгән. Шул исәптән, чик көньяк юнәлештә 3950 метр ераклыкта һәм көньяк-көнчыгыш юнәлештә яки Мартыш торак пункты ягына 5300 метр ераклыкта уза. Мартыш торак пункты сәнәгать мәйданчыгының көнбатыш чигеннән 1550 метр ераклыкта урнашканлактан, Мартыш торак пункты санитар зона чикләренә кергән.

«Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка объектларның санитар-саклау зоналары һәм санитар классификациясе» 2.2.1/2.1.1.1200-03 СанПиН таләпләре нигезендә санитар-саклау зонасында торак төзелешен урнаштыру рөхсәт ителми. Проект чараларын үтәүне, шул исәптән халыкны күчерүне, тиешле сәнәгать объектлары һәм производстволары вазыйфаи затлары тәэмин итә.

«ТАНЕКО» ачык акционерлык җәмгыятенең нефть химиясе һәм нефть эшкәртү заводлары комплексы» проектын гамәлгә ашыру барышы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2010 елның 17 февралендәге 668-ГУ ГС номерлы карары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җирле үзидарә органнары белән берлектә «ТАНЕКО» ААҖ комплексының беренче чиратын файдалануга тапшырыганчы Мартыш авылында яшәүчеләрне Түбән Кама сәнәгать узелының санитар-саклау зонасыннан күчерү мәсьәләсен хәл итүне тизләтү йөкләнде.

Санитар-саклау зонасының ахыргы зурлыгы хисап параметрлары табигый тикшеренүләр һәм үлчәүләр мәгълүматлары белән раслаганнан соң, халык сәламәтлеге өчен куркынычны бәяләгәннән соң билгеләнә. Өстәвенә, табигый тикшеренүләр һәм атмосфера һавасының пычрануын үлчәүләр системалы (еллык) булырга тиеш (һәр ингредиент өчен аерым ноктада ким дигәндә илле көн тикшеренүләр).

2015 елның 1 октябренә Түбән Кама сәнәгать узелының бердәм (хисап) санитар-саклау зонасы чикләренә төзәтү кертү эше төгәлләнде. Түбән Кама сәнәгать узелының бердәм (хисап) санитар-саклау зонасы проектын төзәтү барышында чикләр кимү ягына үзгәрешләр булмады. Киресенчә, көньяк һәм көньяк-көнчыгыш чикләрендә Мартыш авылы урнашкан районда аның артуы ягына төзәтү кертелде.

«Түбән Кама сәнәгать узелы үсеше һәм «ТАНЕКО» ААҖ нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексы конфигурациясе үзгәрү белән бәйле рәвештә (елына 14 млн. тонна нефть эшкәртү), Түбән Кама сәнәгать узелының бердәм хисап санитар-саклау зонасы проектына төзәтмәләр кертү» проект документациясенең дәүләт санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормативларга туры килүе турында Татарстан Республикасы буенча Баш дәүләт санитар табибының 2013 елның 18 сентябрендәге 16.11.11.000.Т.001119.09.13 номерлы бәяләмәсе алынды.

**Йомгаклау нигезләмәләре**

«Татарстан Республикасы нефть-газ-химия комплексын үстерү программасы», шулай ук «Түбән Кама шәһәрендә Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексын төзү турында» Министрлар Кабинеты карарын тормышка ашыру кысаларында, Түбән Кама шәһәре территориясендә гамәлдәге предприятиеләр куәтләрен арттыра, яңа объектлар төзелеше бара.

Мартыш авылы Түбән Кама сәнәгать узелының бердәм (хисап) санитар-саклау зонасы проекты чикләренә керә. Мартыш авылында яшәүче халыкның иминлеге өчен шартлар тудыру мөмкин түгел. СанПиН нигезендә санитар-саклау зонасында кешеләр яшәр өчен объектлар урнаштыру рөхсәт ителми.

Авыл халкының күпчелеге 2013 елда яңа торакка күчерелде. Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча миграция хезмәтенең 2023 елның

29 маендагы 85/3722 номерлы белешмәсе нигезендә хәзерге вакытта Мартыш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар юк.

Татарстан Республикасы буенча «Росреестрның Федераль кадастр палатасы» ФДБУ тарафыннан тәкъдим ителгән җир кишәрлекләре турында кадастр өземтәләре буенча бетерелә торган торак пункт территориясендә гражданнарга яки юридик затларга торак төзелеше яки торак төзелеше максатларында комплекслы үзләштерү өчен бирелгән җир кишәрлекләре юк.

«ТР БТИ» АҖ Яр Чаллы филиалы белешмәсе буенча әлеге территориядә торак корылмалар юк.

**«Татарстан Республикасы Тукай районы Мартышавылын бетерү турында һәм «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителү белән бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Тукай районы Мартыш авылын бетерү һәм «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы закон актларына үзгәрешләр кертү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Тукай районы Мартыш авылын бетерү һәм «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Тукай районы Мартыш авылын бетерү һәм «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итмәячәк.